# *Бариева Хәдия Низами кызы*

*Сугыш башланганда миңа 9-10 яшьләр иде, шунлыктан бик хәтерләп тә бетермим, сугыш башлангач курыкканбыздыр инде.*

*Гаиләдән әтием Җәләлиев Низамины һәм Җаппаров Гани абыйны сугышка озаттык. Әтием 1942 нче елның гыйнварында сугышка китте. Ул вакытта без гаиләдә 8 бала идек, әтисез еллар авыр узды, ачлыкка тилмерә идек.*

*Әни 8 нче балага йөкле булганда, әтинең үлү хәбәрен авыл советлары әйтмичә йөргәннәр. Әнинең табар вакыты җиткәч, хәбәр ишетелде. Без әти үлгән дип еласак, әнинең шушы авыр вакытта бала табасы бар, аларны ничек аякка бастырырмын, дип елады. Шунда күңелем бик әрнеде...*

*Гаиләне туендырыр өчен, әниебез көне-төне эшләде, безнең дә кечкенә вакыттан ук эшләмәгән эш калмады. Әни фермада эшләгәндә мин дә аңа бозауларны имезергә булыша идем дә, аннан сон гына мәктәпкә төшеп китә идем. 7 класс белем алдым. Сугыш вакытында нинди күңелле вакыйгалар булсын инде, бернинди күңелле вакыйгалар булмады.*

*Әтине озатырга әни Сослангерга азык-төлекләр алып барган булган, анда әти булмаган, ләкин алып барган әйберләрен шунда булган солдатларга биреп калдырган инде. Ә болай солдатларга оекбашлар бәйләп җибәрә торган идек. Кораллар ясау өчен акчаны авыл советы кешеләре кереп сорап җыялар иде, барлы-юклы акчаны да бирә идек.*

*Мин үзем пионер булып йөрдем, комсомол була алмадым. Комсомолга безгә кучәргә ярамый иде.*

*Җиңү турында мин мәктәптә ишеттем. Чәршәмбе көн иде ул. Урыс үртәме авылы марҗалары сугыш бетте, дип частушкалар җырлап куанып йөрделәр. Без дә куандык инде сугыш беткәнгә.*

*Сугыштан соң азрак хәлләндек, яшәдек инде әкренләп. 5 ел почтада эшләдем.*

*Минем яшьләргә әйтер сүзем шул: исән-сау, игелекле, бәхетле булсыннар, сугышлар күрмәсеннәр. Тыныч илдә тыныч кына, матур гына яшәсеннәр.*